**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 1 март № 124

г. Казань

Татарстан Республикасы бюджетының расланган бюджет ассигнованияләре составында резервка калдырылган акчаны куллану тәртибен (куллану турында, яңадан бүлү хакында карарлар кабул итү тәртибен) раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 217 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы бюджетының расланган бюджет ассигнованияләре составында резервка калдырылган акчаны куллану тәртибен (куллану турында, яңадан бүлү хакында карарлар кабул итү тәртибен) расларга.
2. Бу карарның көче 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\124.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 1 март, 124 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы бюджетының расланган бюджет ассигнованияләре составында резервка калдырылган акчаны куллану тәртибе (куллану хакында, яңадан бүлү хакында карарлар кабул итү тәртибе)**

1. Әлеге Татарстан Республикасы бюджетының расланган бюджет ассигнованияләре составында резервка калдырылган акчаны куллану тәртибе (куллану турында, яңадан бүлү хакында карарлар кабул итү тәртибе) Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы бюджетының расланган бюджет ассигнованияләре составында резервка калдырылган акчаны (алга таба – резервка калдырылган акча) куллану механизмнарын билгели, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасыннан гайре.

2. Резервка калдырылган акчаны куллану күләме һәм юнәлешләре тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында билгеләнә.

3. Резервка калдырылган акчаны куллану (яңадан бүлү) турында карарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы рәвешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кабул итә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резервка калдырылган акчаны куллану (яңадан бүлү) турында боерыклары проектларын әзерләү, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең мәнфәгатьле башкарма органнары белән килештерүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Резервка калдырылган акчаны кулланган (яңадан бүлгән) очракта Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язуын төзү һәм алып баруның билгеләнгән тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язуына үзгәрешләр кертелә.

6. Резервка калдырылган акчаны куллану аларның максатчан билгеләнеше нигезендә гамәлгә ашырыла һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасын төп бүлүчеләр, бүлүчеләр һәм алучылар тарафыннан бюджет чыгымнары классификациясенең тиешле бүлекләре буенча айлык, квартал һәм еллык хисаплылык составында чагылыш таба.

---